Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр
башкарма комитеты

422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Исполнительный комитет
города Арск
422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

# КАРАР

« 30 » сентябрь 2024 ел № 146

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге территорияләрендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестрына һәм схемасына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы (25.12.2018 елгы редакция), «Каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары нигезендә, Арча шәһәре Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 17 гыйнварындагы 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестрына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Арча шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 17 гыйнварындагы 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннарының схемасына 2 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф.Касыймов

Арча шәһәре
башкарма комитетының
30 сентябрь 2024 ел, №146
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестры

| № | Контейнер мәйданчыгының адресы | Киңлек | Озынлык | ККК барлыкка килү чыганаклары | ККК өчен контейнер мәйданчыгын җиһазлау | | | | ККК туплану урыннары милекчеләре турында мәгълүматлар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Контейнерлар (бункерлар) саны , данә | Контейнер (бункер) күләме, м³ | Җиһазлау | | |
| | | | | | | | Нигез | Койма булу | |
| 123 | Арча ш., К. Тинчурин урамы, 52 йорт | 56.099676 | 49.855505 | Арча ш., К. Тинчурин урамы | 2 | 1,1 | бар | юк | "Арча шәһәре" МБ |
| 204 | Арча ш., Бакый Урманче урамы, 18 йорт | 56.103365 | 49.881267 | Арча ш., Бакый Урманче урамы, 18 йорт | 3 | 1.1 | бар | 204 | Арча ш., Бакый Урманче урамы, 18 йорт |

Арча шәһәре
башкарма комитетының
30 сентябрь 2024 ел, №146
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннарының схемасы

